КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 май г.Казань № 371

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү тәртибен һәм программасын раслау турында» 2012 ел, 20 октябрь, 878 нче карары белән расланган Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү тәртибен һәм программасын раслау турында» 2012 ел, 20 октябрь, 878 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 май, 320 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 20 октябрь, 878 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 8 май, 371 нче
карары редакциясендә)

# Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасы

## I. Курсның максатлары һәм бурычлары

Курсның максатлары: гражданнарны ата-ана, законлы вәкил функциясен гамәлгә ашыруга социаль-психологик-педагогик әзерләү, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы гаиләгә алу турында аңлы рәвештә кабул ителгән карар булдыру; гаиләдә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы тәрбияләүдән баш тарту рискын киметү.

Курсның бурычлары:

психологик, педагогик, юридик һәм медицина белемнәрен үзләштерүдә, шулай ук ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны тәрбияләүгә үзенең психологик әзерлеген аңлауда ярдәм күрсәтү;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы гаиләгә алу алдыннан гаилә системасы ресурсларын бәяләгәндә ярдәм күрсәтү;

гаиләдә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы уңышлы тәрбияләү һәм социальләштерү өчен кирәкле күнекмәләр үзләштерүне тәэмин итү;

гражданнарга ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар белән шәхесара конструктив мөнәсәбәтләр урнаштыру осталыгын һәм күнекмәләрен өйрәтү;

дәресләр барышында мәгълүмат алу һәм үзләштерү һәм белем алучылар арасында бердәм киңлек булдыру өчен шартлар тудыру;

гражданнарга ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру буенча гаиләләрдә аларның адаптациясен тәэмин итүче хезмәтләр турында мәгълүмат бирү.

## II. Дәресләрне оештыру формалары

Укыту көндезге яки көндезге-читтән торып уку формасында, шулай ук дистанцион укыту формасын кулланып алып барыла.

Көндезге уку формасы – опека һәм попечительлек органы яки ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләүне үткәрү вәкаләтләре тапшырылган оешма белгечләре тарафыннан расланган расписание буенча оештырылган аудитория дәресләрендә (лекцияләрдә, тренингларда һәм семинарларда) мәҗбүри булуны күз тоткан әзерләү формаларының берсе. Көндезге уку формасы буенча дәресләр мини-лекцияләр, семинарлар, тренинг

элементлары белән практикумнар, рольле һәм эшлекле уеннар, индивидуаль һәм төркем консультацияләре рәвешендә үткәрелә. Лекцияләрдә гражданнар семинарларда һәм практикумнарда ныгытыла торган кирәкле белемнәрне ала. Дәресләрдә кулланыла торган ысуллар уку курсының тематикасына карап үзгәрә һәм практик мәсьәләләрне тикшерү һәм чишүне үз эченә ала.

Көндезге-читтән торып уку формасы аудиториядә башкарыла торган эшне һәм мөстәкыйль эшне (өй эшләрен) күздә тота. Граждан белгечләр тәкъдим иткән материаллар белән эшли, контроль һәм тест биремнәрен үти. Көндезге-читтән торып уку формасында мөстәкыйль эшне (контроль биремнәр, эссе һ.б.) зур күләмдә башкару карала.

Дистанцион әзерләү формасы – уку материалын бирү, аны мөстәкыйль өйрәнү, уку процессында катнашучылар арасында диалог белән алмашу өчен кулланыла торган традицион һәм яңа мәгълүмат технологияләренең киң спектрын файдалануга нигезләнә торган укытуны оештыру формасы. Дистанцион форма интернет-технологияләрнең киң спектрын (ресурс булганда) куллану ярдәмендә оештырыла. Дистанцион әзерләү – ул укытуның бер өлеше булырга мөмкин, әмма укытуның башка формаларын алмаштыра алмый. Контроль биремнәрне үтәү нәтиҗәләре белгеч тарафыннан тикшерелә, шуның нигезендә гражданның әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә ясала.

Төркем эше башланганга кадәр тәрбиягә бала алучы ата-аналар булырга кандидатларның һәрберсе (алга таба – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар) белән баланы гаиләгә тәрбиягә алуның мотивларын, аннан көтелә торган өметләрне ачыклау, бала алуның хокукый һәм башка нәтиҗәләрен, гаилә ресурсларын (гаиләдә бала тәрбияләүгә ярдәм итәчәк матди, социаль һәм психологик шартларны) аңлау максатларында индивидуаль әңгәмә (структурлаштырылган әңгәмә) үткәрелә.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү дәрәҗәсенә карата таләпләр:

гражданның түбәндәгеләр турында төгәл күзаллавы булырга тиеш:

балалар хокукларын яклау системасы, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы гаиләгә тәрбиягә урнаштыру формалары турында;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы гаиләгә әзерләү һәм алу барышында булышлык күрсәтүче оешма һәм гаилә, гаиләләргә финанс ярдәме күрсәтү турында;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган затларның аның гомере һәм сәламәтлеге, аны тәрбияләү һәм үстерү өчен җаваплылыгы турында;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның үзенчәлекләре һәм үткән тормыш тәҗрибәсенең (депривация, рәхимсез мөгамәлә, бала ихтыяҗларына игътибар итмәү, биологик гаилә белән аерылышу) психофизик үсешенә һәм тотышына йогынтысы турында;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның яшенә бәйле ихтыяҗларына, тормыш тәҗрибәсенә карап, аларны имин тәрбияләү кагыйдәләре турында;

өйдә дә, өйдән чыккач та – урамда, җәмәгать урыннарында иминлекне тәэмин итү турында;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы алуга шулай ук җайлашучы үсә торган система буларак үз гаиләсе турында;

ата-анага кирәкле тәрбия бирү компетенцияләре (кыйммәтләре, белемнәре һәм осталыклары) турында;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың үзенең ата-анасы һәм туганнары белән элемтәләргә керү тәртибе турында;

граждан түбәндәгеләрне белергә тиеш:

үз гаиләсенә бала алган затларның ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балага карата да, булышлык күрсәтүче оешмага карата да хокукларын һәм бурычларын;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың төрле яшь чорларында үсеш законгалыкларын һәм ихтыяҗларын;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың аның нормаль үсеше өчен нигез булган тәңгәллеккә һәм эмоциональ иләшүгә ихтыяҗын канәгатьләндерү мөһимлеген;

эмоциональ һәм социаль депривациянең барлыкка килү, күренә башлау һәм нәтиҗәләре сәбәпләрен;

кайгы кичерү этапларын һәм үзенчәлекләрен, кайгы кичерүнең төрле этапларында ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балага ярдәм күрсәтү мөмкинлекләрен;

яңа гаиләдә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың адаптацияләү чоры үтү үзенчәлекләрен;

ата-ананың үз тәҗрибәсе ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның «авыр» үз тотышына карата мөнәсәбәтенә йогынты ясавы турында;

гаиләдә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны тәрбияләү буенча санитария-гигиена кагыйдәләрен һәм нормаларын;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың яшенә, тормыш тәҗрибәсенә һәм үзенчәлекләренә карап, аның социаль-көнкүреш осталыкларын формалаштыру алымнарын;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың яшенә бәйле җенси үсешенең психофизиологик үзенчәлекләрен, гаиләдә җенси тәрбия бирү ысулларын һәм алымнарын;

граждан түбәндәгеләрне белергә тиеш:

үзендә булган үз тәрбия бирү компетенцияләрен анализлау, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә алу өчен үз әзерлеген, үзенең дә һәм гаиләнең дә ресурсларын һәм чикләүләрен аңлау һәм бәяләү өчен алган белемнәрен куллана;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы тәрбияләү буенча үз тәрбия бирү компетенцияләрен компенсацияләү, формалаштыру һәм камилләштерү мөмкинлекләрен күрә;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың «авыр» үз тотышын әйләнәтирә шартлар һәм аның травмалы үткән тормыш тәҗрибәсе контекстында карый;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың үсеш үзенчәлекләренә, тормыш тәҗрибәсенә һәм агымдагы хәлгә карап, «авыр» үз тотышка карата чара күрү алымнарын сайлап ала;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың «авыр» үз тотышына карата үз хисләренең табигатен аңлый;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, кайгы һәм югалту кичергән балага ярдәм итәргә әзер була;

үз гаиләсендә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала белән рәхимсез мөгамәләдә булу рискын бетерә;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың тормышы, сәламәтлеге һәм психологик иминлеге өчен мөмкин булган рискны бәяли һәм өйдәге имгәнүләрне булдырмый торган имин яшәү мохите тудыра;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала тормышында ата-анасы һәм үз туганнары урынын кабул итүгә бәйле фикер йөртү стереотипларын җиңә;

гаиләгә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала килгәннән соң, үз гаилә системасы үзгәрүен фаразлый;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың үсеш ихтыяҗлары һәм үз гаиләсенең мөмкинлекләре арасындагы бәйләнешләрне аңлый;

үз гаиләсенең тәрбия бирү ресурсын бәяли;

тәрбия бирү барышында башка гаилә әгъзалары белән хезмәттәшлек итәргә әзер була;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ата-аналарга, законлы вәкилләргә һөнәри ярдәм һәм булышлык күрсәтү системасында ориентлаша;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың сәламәтлеге турында кайгырта;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балага карата конфиденциальлекне саклый;

нормаль балалар сексуальлеге һәм сексуальләшкән үз тотыш күренешләре арасындагы аерманы аңлый;

кризислы хәлләрдән конструктив чыгу юлларын таба, авырлыклар булган очракта, ярдәм күрсәтүне сорап, белгечләргә мөрәҗәгать итә.

## III. Укыту-тематик планы

| Т/с | Бүлекнең исеме | Сәгатьләр саны | Лекцияләр | Тренинглар | Индивидуаль консультацияләр бирү |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Тәрбиягә бала алучы ата-ана булырга кандидатларны әзерләү курсына кереш | 6 | | 5 | 1 |
| 2. | Тәрбиягә алынган баланың үсеш ихтыяҗлары турында һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарның кирәкле компетенцияләре турында күзаллау. Тәр- | 8 | | 8 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | биягә бала алучы ата-аналарның мотивациясе турында төшенчә | | | | |
| 3. | Баланың үсеш этаплары | 4 | 2* | 2 | |
| 4. | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган һәм рәхимсез мөгамәләгә дучар булган баланың үсеш һәм үз-үзен тотыш үзенчәлекләре. Баланың үсеш диспропорциясе | 6 | | 6 | |
| 5. | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың үсеше өчен туган гаиләсе белән аерылышу нәтиҗәләре (ияләшү бозылу, кайгы һәм югалтуны кичерү үзенчәлекләре, шәхси һәм гаилә тәңгәллеген формалаштыру) | 15 | | 15 | |
| 6. | Тәрбиягә алынган баланың һәм тәрбиягә бала алган гаиләнең адаптациясе | 2 | | 2 | |
| 7. | Тәрбиягә алынган баланың «авыр» үз тотышы, баланың «авыр» үз тотышы белән идарә итү күнекмәләре | 8 | 2* | 6 | |
| 8. | Баланың иминлеген тәэмин итү. Бала белән рәхимсез мөгамәләдә булу һәм аның сәламәтлегенә зыян китерү рискларын булдырмау чаралары | 8 | 6 | 2 | |
| 9. | Тәрбиягә алынган балага җенси тәрбия бирү үзенчәлекләре | 2 | | 2 | |
| 10. | Баланың үсеш ихтыяҗларын тәэмин итүдә һәм аны тернәкләндерүдә гаиләнең роле | 9 | 3* | 6 | |
| 11. | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гражданнар гаиләсенә тәрбияләүгә урнаштыру турында Россия Федерациясе законнары нигезләре | 7 | 7 (4*+3) | 0 | |
| 12. | Тәрбиягә бала алган гаиләнең опека һәм попечительлек органнары һәм балаларга һәм | 2 | 1* | 1 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | гаиләләргә хезмәтләр күрсәтүче башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге | | | | |
| 13. | Тәрбиягә бала алучы ата-ана булырга кандидатлар әзерләү курсын үзләштерүгә йомгаклар ясау | 3 | | 2 | 1 |
| | Барлыгы | 80 | 21 (12*) | 57 | 2 |

* Бу лекцияләрдә дистанцион укыту ысуллары кулланылырга мөмкин.

## IV. Темалар программасы

### Бүлек 1. Тәрбиягә бала алучы ата-ана булырга кандидатларны әзерләү курсына кереш

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасының эчтәлеге, максатлары һәм аны үткәрү этаплары.

Әзерлек бурычлары, шул исәптән түбәндәгеләргә кагылышлы:

ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны (алга таба – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар) карап тоту һәм тәрбияләү, шул исәптән аларның хокукларын яклау һәм сәламәтлеген саклау, имин мохит булдыру, уңышлы социальләштерү, аларга белем бирү һәм үстерү өчен тәрбияләү компетенцияләрен, шулай ук ата-аналар күнекмәләрен ачыклауга һәм формалаштыруга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларга үзләренең ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы тәрбиягә алырга әзерлеген билгеләүдә, баланы гаиләгә тәрбиягә урнаштыру формасын сайлауда, үзләренең көчсез һәм көчле якларын, баланы тәрбияләүдә шәхси һәм тулаем алганда гаиләнең ресурсларын һәм чикләүләрен ачыклауда, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы тәрбияләү процессында алар дучар булачак реаль проблемаларны һәм кыенлыкларны, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар җаваплылыгын аңлауда ярдәм күрсәтүгә;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы гаиләгә урнаштыруның гамәлдәге формалары белән һәм балалар хокукларын яклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезләре, шулай ук аларның ата-аналар, законлы вәкилләр буларак хокуклары һәм бурычлары белән таныштыруга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларда балалар психологиясе, бала үсеше һәм аның үткән тормыш тәҗрибәсенең (депривация, рәхимсез мөгамәлә, бала ихтыяҗларына игътибар итмәү,

биологик гаилә белән аерылышу) психофизик үсешенә һәм үз тотышына йогынты ясавы өлкәсендә белемнәр булдыруга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларда система буларак гаилә турында һәм бала барлыкка килгәннән соң андагы үзгәрешләр турында күзаллаулар формалаштыруга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны гаиләдә баланың адаптация чоры үтү үзенчәлекләре, шулай ук баланың «авыр» үз тотышы сәбәпләре һәм мондый тәртипне җиңү ысуллары белән таныштыруга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны баланың сәламәтлеген саклау һәм аңа имин тәрбия бирүне оештыру буенча йөкләмәләр белән таныштыруга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы тәрбиягә алган гаиләләргә һөнәри ярдәм күрсәтү, ярдәм итү һәм булышлык күрсәтүнең гамәлдәге формалары белән таныштыруга.

Укыту-психологик тренинг төшенчәсе, аны үткәрү барышында кулланыла торган алымнар; ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче, әзерлек курсын үзләштерүче затларны һәм аларның гаилә әгъзаларын психологик тикшерү һәм тренинг нигезендә әзерләү (аны үткәргән очракта) үзенчәлекләре һәм тәртибе турында; контакт төшенчәсе һәм тренингта катнашучылар арасында контакт формалаштыруның практик күнекмәләрен эшләү.

Балаларның ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калу сәбәпләре, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда балалар контингенты, баланы потенциаль гаилә белән танышу процедурасы.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның гаилә законнары белән билгеләнгән гаилә формаларының гомуми тасвирнамәсе, аларның аерымлыклары һәм үзенчәлекләре.

## 2 бүлек. Тәрбиягә алынган баланың үсеш ихтыяҗлары турында һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарның кирәкле компетенцияләре турында күзаллау. Тәрбиягә бала алучы ата-аналарның мотивациясе турында төшенчә

Баланың үсеш ихтыяҗларын өйрәнү (физиологик, куркынычсызлык, сәламәтлек, белем бирү, акыл үсеше, ияләшкән булу, эмоциональ үсеш, тәңгәллек, баланы кабул иткән яңа гаиләдә тотрыклы мөнәсәбәтләр, социаль адаптация – үз тотышның социаль нормаларын һәм кагыйдәләрен, социаль рольләрне үзләштерү, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләре – санитария-гигиена һәм көнкүреш күнекмәләре) һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның аларны тәэмин итү кирәклеген аңлавы. Баланың физиологик ихтыяҗларына игътибар итмәү, иминлеккә, кабул итүгә, ихтирамга ихтыяҗ булу нәтиҗәләре.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның мотивация төрләре. Мотивациянең ата-ана кайгыртуыннан

мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган гаилә эшчәнлеге үзенчәлекләре белән бәйләнеше.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләрендәге проблемалар чыганагы буларак бала уңышларга ирешү планында көтелә торган зур өметләре.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың аерым ихтыяҗларына бәйле мәсьәләләр буенча мәктәпкәчә учреждение яки мәктәп педагоглары белән үзара хезмәттәшлек итү.

Гаиләнең тормыш шартларын (халыкка хезмәт күрсәтүләр инфраструктурасыннан ерак булуы, матди-көнкүреш шартлары, эш белән тәэмин ителеше, кереме) һәм гаилә системасының үзенчәлекләрен исәпкә алып, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар тарафыннан баланың үсеш ихтыяҗларын тәэмин итүгә үз сәләтен бәяләү.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның бала тәрбияләү буенча үзләрендә булган компетенцияләрне бәяләү, җитмеп бетмәгән компетенцияләрне формалаштыру юлларын һәм мөмкинлекләрен эзләү.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның гаиләгә сиблинглар, яшүсмерләр яшендәге балаларны алу өчен үзләрендә булган ресурсларын бәяләү.

Бала эзләү һәм сайлау. Бала белән танышу.

## 3 бүлек. Баланың үсеш этаплары

Бала үсешенең яшенә бәйле төп чорларының (сабыйлык, кече яшьтәге, мәктәпкәчә яшьтәге, кече мәктәпкәчә яшьтәге, үсмер яшендәге, яшүсмер чоры) гомуми тасвирнамәсе.

Шәхси үсештә психологик ихтыяҗларның роле: ияләшкәнлек, куркынычсызлык, тәңгәллек.

## 4 бүлек. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган һәм рәхимсез мөгамәләгә дучар булган баланың үсеш һәм үз-үзен тотыш үзенчәлекләре. Баланың үсеш диспропорциясе

Рәхимсез мөгамәлә итү төрләре (бала ихтыяҗларын үтәмәү, физик, психологик һәм сексуаль көчләү) һәм баланың физик, эмоциональ, интеллектуаль, социаль һәм сексуаль үсеше өчен алар бирә торган нәтиҗәләр.

Гаилә рәхимсез мөгамәлә кичергән бала өчен тернәкләндерү факторы буларак.

Баланың үсеш диспропорциясе. «Акыл үсеше артта калу» һәм «психик үсешендә тоткарлык» төшенчәләре, аларның аерымлыклары.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның рәхимсез мөгамәлә кичергән баланы тәрбияләүгә үз мөмкинлеген бәяләү.

Өйдә һәм җәмгыятьтә бала тәрбияләү өчен, аның яшь үзенчәлекләренә һәм тормыш тәҗрибәсенә карап (шул исәптән ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган ба-

лалар өчен оешмаларда тәрбияләүгә, ата-ана гаиләсендә күзәтүчесезлеккә, сукбайлыкка бәйле рәвештә), имин шартлар тудыру.

Бала белән рәхимсез мөгамәлә кылу рискы булган хәлләрдә аның үз-үзен имин тоту ысуллары.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган затлар гаиләсендә, урамда һәм җәмәгать урыннарында бала белән рәхимсез мөгамәлә кылу рискларын булдырмау.

Балалар – көчләү корбаны булу рискы югары булган төркем буларак рәхимсез мөгамәлә корбаннары. Аерым ихтыяҗлары булган балаларның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча балалар учреждениесе яки мәктәп педагоглары белән үзара хезмәттәшлек итү.

## 5 бүлек. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың үсеше өчен туган гаиләсе белән аерылышу нәтиҗәләре (ияләшү бозылу, кайгы һәм югалтуны кичерү үзенчәлекләре, шәхси һәм гаилә тәңгәллеген формалаштыру)

Баланың имин үсеше нигезе буларак ияләшүгә, тәңгәллеккә ихтыяҗ. Бала тормышында биологик ата-анасының һәм кардәш туганнарының роле һәм бала тормышында аларның урынын кабул итүгә бәйле фикер йөртү стереотипларын җиңү.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балада эмоциональ депрессия барлыкка килү, күренү һәм нәтиҗәләренең сәбәпләре.

«Бозылган ияләшкәнлек» типлары («негатив (неврологик) ияләшкәнлек», «амбивалент ияләшкәнлек», «качып йөрүле ияләшкәнлек», «оешмаган ияләшкәнлек» төшенчәләре).

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала тормышында «кайгы һәм югалту» төшенчәсе. Баланың гаиләсен югалтуга (шок, тетрәнү һәм ышанычсызлык, кире кагу, ачу һәм хисләр катнашу стадиясе, депрессия, кабул итү) бәйле кичерү процессының психологик үзенчәлекләре һәм этаплары.

Кардәш туганнары белән аралашу – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган затларның роле нидән гыйбарәт?

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган затларның баладан икенче тапкыр баш тарту нәтиҗәләре.

Дәүләт учреждениеләрендә тәрбияләнүче балаларның психологик үзенчәлекләре (институтлаштыру).

## 6 бүлек. Тәрбиягә алынган баланың һәм тәрбиягә бала алган гаиләнең адаптациясе

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә алган гаиләләрнең өмет итү үзенчәлекләре. Төрле адаптация чорларында өлкәннәрнең куркулары, борчылулары һәм өметләре өзелү.

Туганнарны ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала булуга әзерләү.

Өйне әзерләү.

Адаптация чоры этаплары. Гаиләгә килүче баланың хисләре һәм кичерешләре. Адаптация кыенлыкларын җиңү ысуллары.

Сиблинглар гаиләсендә адаптация үзенчәлекләре.

Баланың яңа гаиләдә адаптация үтү чорында ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы тәрбиягә алган гаиләләргә ярдәм күрсәтүдә белгечләрнең роле.

7 бүлек. Тәрбиягә алынган баланың «авыр» үз тотышы,
баланың «авыр» үз тотышы белән идарә итү күнекмәләре

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың «авыр» үз тотышы формалары: караклык, ялган, агрессия, теләнчелек, сукбайлык, якын мөнәсәбәтләрдән качу, амбивалент тотыш, аддиктив тотыш (алкоголь, наркотиклар, көчле тәэсир итүче матдәләр куллану). Аларның сәбәпләре һәм алар белән эшләү ысуллары.

Балага җәза бирү һәм аны хуплау нәтиҗәлелеге һәм урынлы булуы; баланың этик кыйммәтләрне һәм иҗтимагый нормаларны үзләштерүен тоткарлау сәбәпләре.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган затларның үз тәҗрибәсе «авыр» үз тотышлы балалар белән мөнәсәбәтенә йогынты ясавын аңлау, үзләренең зәгыйфь һәм көчле якларын аңлау, «авыр» үз тотыш проблемаларын хәл итүдә белгечләр ярдәменең әһәмиятен аңлау.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың «авыр» үз тотышы мәсьәләләре буенча балалар бакчасы яки мәктәп педагоглары белән үзара хезмәттәшлек итү.

8 бүлек. Баланың иминлеген тәэмин итү.
Бала белән рәхимсез мөгамәләдә булу һәм аның сәламәтлегенә зыян китерү рискларын булдырмау чаралары

Өйдә һәм җәмгыятьтә бала тәрбияләү өчен аның яшь үзенчәлекләренә һәм тормыш тәҗрибәсенә карап (шул исәптән ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүгә, ата-ана гаиләсендә күзәтүчесезлеккә, сукбайлыкка бәйле рәвештә) имин шартлар тудыру.

Бала белән рәхимсез мөгамәлә кылу рискы булган хәлләрдә аның үз-үзен имин тоту алымнары.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган затлар гаиләсендә, урамда һәм җәмәгать урыннарында бала белән рәхимсез мөгамәлә кылу рискларын булдырмау.

Балалар – көчләү корбаны булу рискы югары булган төркем буларак рәхимсез мөгамәлә кылу корбаннары. Аерым ихтыяҗлары булган баланың иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча мәктәпкәчә учреждение яки мәктәп педагоглары белән үзара хезмәттәшлек итү.

Баланың яшенә, сәламәтлеге торышына һәм үсешенә карап, аны карауның медицина аспектлары. Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларның сәламәтлеге торышы үзенчәлекләре.

Балалар неврологиясе: сораулар һәм җаваплар.

Баланың психик үсеше тоткарлану һәм аның үсешенә кагылышлы нейропсихологик үзенчәлекләр, аерымлыклар һәм дифференциация.

ВИЧ-инфекцияле һәм ВИЧ-контактлы баланы карау үзенчәлекләре.

Иртә балалар аутизмы булган баланың үзенчәлекләре. Иртә балалар аутизмы һәм депривация, аерымлыклар һәм дифференциация.

Энурез, авыру барлыкка килүнең органик һәм психоэмоциональ сәбәпләре.

Феталь алкоголь синдромы, феталь алкоголь синдромының тышкы билгеләре, барлыкка килү сәбәпләре.

Гиперактивлы игътибар кытлыгы синдромы, баланың үз тотышын коррекцияләү алымнары.

## 9 бүлек. Тәрбиягә алынган балага җенси тәрбия бирү үзенчәлекләре

Баланың психосексуаль үсеше үзенчәлекләре һәм яшенә бәйле закончалыклар, нормаль балалар сексуальлеге һәм сексуальләшкән үз тотыш күренешләрендәге аерма. Баланың җенси тәңгәллеген формалаштыру. Җенси роль юнәлешен бирү һәм җенескә каравын аңлату.

Балаларны җенси көчләүдән саклау алымнары.

Сексуаль көчләүгә дучар ителгән баланың сексуальләшкән үз тотышы.

## 10 бүлек. Баланың үсеш ихтыяҗларын тәэмин итүдә һәм аны тернәкләндерүдә гаиләнең роле

Гаилә система буларак. Баланың гаилә системасында урыны. Балага карата ата-ана мөнәсәбәте һәм аның баланы шәхес итеп формалаштыруга һәм характерына йогынтысы.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларда гаилә мөнәсәбәтләренең тотрыклылыгы.

Гаиләгә бала алуның мотивация аспектларына гаилә тарихының йогынтысы.

Гаиләнең стресс хәлләргә карата чара күрү алымнары.

Гаилә тернәкләндерүче мохит буларак: гаиләнең яшәү рәвеше, гаилә көнкүреше, гаилә традицияләре.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның барлык әгъзалары тарафыннан үз гаиләсе проблемаларын, үз мөмкинлекләрен һәм ресурсларын, көчле һәм зәгыйфь якларны аңлау.

Уллыкка (кызлыкка) алу сере. Аның реаль һәм уйдырма өстенлекләре һәм авырлыклары. Балага аның туган булмавы турында әйтү алымнары.

Бала тормышында биологик ата-ананың һәм кардәш туганнарның роле һәм бала тормышында аларның урынын кабул итүгә бәйле фикер йөртү стереотипларын җиңү.

Сиблингларны үз гаиләсенә тәрбиягә алган затлар гаиләсендә аларның үзара аралашуы.

## 11 бүлек. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гражданнар гаиләсенә тәрбияләүгә урнаштыру турында Россия Федерациясе законнары нигезләре

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның хокукый хәле һәм аларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру нигезләре.

Гаилә кору формалары: уллыкка (кызлыкка) алу, опека (попечительлек), тәрбиягә бала алган гаилә. Опека формалары (түләүле һәм түләүсез). Гаилә кору формалары арасында аермалар.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә алырга теләүче затларга карата Россия Федерациясе законнары белән куела торган таләпләр. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә алырга теләүче затлар тарафыннан гражданның уллыкка алучы, опекун (попечитель) яки тәрбиягә бала алучы ата-ана булу мөмкинлеге турында бәяләмә алу өчен документлар бирү тәртибе.

Опека һәм попечительлек органнары, төбәк һәм федераль операторлар тарафыннан ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар турында дәүләт мәгълүматлар банкын, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар турында белешмәләр бирү тәртибе.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булу кагыйдәләре, мондый оешма администрациясенең бурычлары.

Балага бәйсез медицина тикшерүе үткәрү мөмкинлеге.

Суд тарафыннан баланы уллыкка алу турында карар кабул итү тәртибе. Судка гариза әзерләү һәм бирү тәртибе. Уллыкка алу серләренең хокукый аспектлары. Баланың фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен һәм урынын үзгәртү мөмкинлеге һәм аның нәтиҗәләре.

Опека һәм попечительлек органы һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешма тарафыннан гаиләгә тәрбиягә бирелә торган балага, аның урнашу формасына карап, документларны рәсмиләштерү тәртибе, гаиләгә бирелә торган баланың документлар исемлеге.

Баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турындагы карар үз көченә кергәннән соң, уллыкка алучы, опекун (попечитель) тарафыннан баланың документларын рәсмиләштерү (яңадан рәсмиләштерү) тәртибе.

Гаиләләргә һәм аларда тәрбияләнүче балаларга Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль ярдәм чаралары. Гаилә корылышы формасына карап, гаиләгә тәрбиягә бирелгән баланы карап тотуга карата башкарыла торган түләүләр.

Баланың шәхси милек булмаган һәм милек хокукларын яклау.

Опека һәм попечительлек органнары тарафыннан опекуннар (попечительләр), уллыкка алучылар, тәрбиягә бала алучы ата-аналар гаиләсендә баланың яшәү һәм тәрбияләү шартларын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе.

Опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алучы ата-аналар тарафыннан ел саен балигъ булмаган баланың мөлкәтен саклау, файдалану һәм мондый мөлкәт белән идарә итү турында хисап бирү тәртибе.

Уллыкка алуның, опека (попечительлек) билгеләүнең хокукый нәтиҗәләре – шәхси милек булмаган һәм милек хокуклары, уллыкка алучыларның, опекуннарның (попечительләрнең), тәрбиягә бала алучы ата-аналарның, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының бурычлары һәм җаваплылыгы.

Бала тарафыннан – тәрбиягә бала алган гаиләгә, тәрбиягә бала алган гаилә тарафыннан – балага, өченче затлар тарафыннан тәрбиягә бала алган гаиләгә һәм балага салынган зыянны каплау тәртибе.

Уллыкка алу, опека һәм попечительлекне бетерү нәтиҗәләре.

ВИЧ-инфекцияле пациентларга һәм ВИЧ-инфекцияле аналардан туган балаларга социаль ярдәм чаралары. ВИЧ-инфекция диагнозын кую кагыйдәләре. Диагноз сере. Дәүләт гарантияләре. ВИЧ белән яшәүче затларга социаль ярдәм итү һәм булышлык күрсәтү.

Опека һәм попечительлек органнары, Россия Федерациясенең гомуми юрисдикциядәге судлары карарларына карата шикаять бирү тәртибе.

## 12 бүлек. Тәрбиягә бала алган гаиләнең опека һәм попечительлек органнары һәм балаларга һәм гаиләләргә хезмәтләр күрсәтүче башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә алган гаиләнең ата-ана һәм һөнәри функцияләре.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә алган гаиләнең опека һәм попечительлек органнары, мондый гаиләләргә медик-социаль һәм психологик-педагогик ярдәм күрсәтүче оешмалар, баланың биологик гаиләсе белән үзара аралашуы, мондый аралашуның мөһимлеге.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларга гаиләнең яшәү урыны буенча тәрбиягә бала алган гаиләләр өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык инфраструктурасы турында мәгълүмат бирү.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы алган гаиләләрнең социаль әйләнә-тирә һәм ата-аналар берләшмәсе белән үзара багланышлары.

## 13 бүлек. Тәрбиягә бала алучы ата-ана булырга кандидатлар әзерләү курсын үзләштерүгә йомгаклар ясау

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар тарафыннан әзерләү курсы материалларын үзләштерү, өй биремнәрен үтәү нәтиҗәләре буенча фикер алышу.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар тарафыннан әзерләү курсы материалларын үзләштерү дәрәҗәсе буенча фикер алышу.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар белән үз-үзенә бәя бирүне үткәрү һәм аларның тәрбиягә бала алырга әзерлеген ачыклау.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларның үз гаиләсенә тәрбиягә бала алырга әзерлеге һәм сәләте турында йомгаклау бәяләмәсен төзү (ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар белән бергәләп, аларның теләге белән төзелә).

___